**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО
РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станция Высокая Гора,
Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Кооперативная ур, 5, Биектау т/ю станциясе поселогы,
Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-61, факс: 2-30-86, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**
**от 16.05.2023** **№ 583**

**«2023 - 2030 елларга Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районында Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» муниципаль программасын раслау турында**

«Россия Федерациясе халыклары телләре турында» 1991 елның 25 октябрендәге 1807-1 номерлы Россия Федерациясе Законы, Россия Федерациясе Президентының 2012 елның 19 декабрендәге 1666 номерлы Указы белән расланган 2025 елга кадәр чорга Россия Федерациясе дәүләт милли сәясәте стратегиясе, «Татарстан Республикасы дәүләт телләре һәм Татарстан Республикасында башка телләр турында» 1992 елның 8 июлендәге 1560-XII номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2023 - 2030 елларга Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» дәүләт программасын раслау турында» 2020 елның 10 сентябрендәге 821 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы дәүләт телләренең һәм Татарстан Республикасында башка телләрнең функциональлеген саклау, өйрәнү, үстерү һәм арттыру, шулай ук Россия Федерациясенең Биектау районына беркетелгән регионнарында татар телен саклау, өйрәнү һәм үстерү өчен шартлар тудыру максатларында, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Кушымтада бирелгән «2023 - 2030 елларга Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районында Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» муниципаль программасын расларга.

2.Әлеге карарны Биектау муниципаль районының рәсми сайтында http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматы порталында http://pravo.tatarstan.ru/бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

3.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны башкарма комитет җитәкчесе урынбасары Р.Р. Сабирҗановка йөкләргә.

Биектау муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе
вазыйфаларын башкаручы Р.Ф. Хәкимуллин

«2023 - 2030 елларга Татарстан Республикасының Биектау муниципаль районында Татарстан Республикасының дәүләт телләрен һәм башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» муниципаль программасы

Программа паспорты

| | |
|---|---|
| Программаның исеме | «2023 - 2030 елларга Татарстан Республикасының Биектау муниципаль районында Татарстан Республикасының дәүләт телләрен һәм башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» муниципаль программасы (алга таба – Программа) |
| Программаның коорди-наторы | Татарстан Республикасының Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты |
| Программаны төп эшләүче | «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге» муниципаль казна учреждениесе |
| Программаның максаты | Биектау муниципаль районында татар, рус һәм башка телләрне, шулай ук Татарстан Республикасыннан читтә (беркетелгән төбәкләрдә) татар телен саклау, өйрәнү һәм үстерү өчен шартлар тудыру |
| Программаның бурычлары | - Татарстан Республикасы дәүләт телләре һәм Татарстан Республикасында яшәүче башка халыкларның телләре эшчәнлеген һәм өйрәнүне оештыру-хокукый һәм аналитик тәэмин итү;<br>- Татарстан Республикасы дәүләт телләре буларак татар һәм рус телләренең паритетлы кулланылуына ярдәм итү;<br>- татар һәм рус телләрен, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районында яшәүче халыкларның башка телләрен өйрәнүнең тулы системасын үстерү; би-һәм полилингваль белем бирү системаларын оештыру һәм укыту-методик озата бару;<br>- Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне популярлаштыруга һәм Татарстан Республикасыннан читтә (беркетелгән регионнарда) зур социаль әһәмиятле чаралар үткәрү;<br>- Интернет-киңлектә уңайлы тел мохите булдыру һәм массакүләм мәгълүмат чараларында туган телләрне популярлаштыру. |
| Программаны тормышка ашыру сроклары һәм этаплары | 2023 – 2030 еллар |

| | |
|---|---|
| Елларга бүленеш белән финанслау күләмнәре | Программаны финанслауның гомуми күләме Биектау муниципаль районы бюджеты акчалары исәбеннән, өстәмә керемнәр булганда, 4 000 000 сум тәшкил итә, шул исәптән:<br>2023 елда – 500 000,<br>2024 елда - 500 000,<br>2025 елда - 500 000,<br>2026 елда - 500 000,<br>2027 елда – 500 000,<br>2028 елда - 500 000,<br>2029 елда – 500 000,<br>2030 елда – 500 000.<br>Искәрмә: финанслау күләмнәре фараз характерында һәм Татарстан Республикасы бюджеты мөмкинлекләрен исәпкә алып, ел саен төзәтмәләр кертелергә тиеш.<br>Программа чараларын гамәлгә ашыруга чараларны башкаручыларның төп эшчәнлеген финанслауга бүлеп бирелә торган акчаларны, бюджеттан тыш акчаларны (эшкуарлар, иганәчеләр акчалары) һәм муниципаль берәмлек бюджеты акчаларын файдалану күздә тотыла. |
| Программаны тормышка ашыруның көтелгән ахыргы нәтиҗәләре (Программаның нәтиҗәләрен бәяләү индикаторлары) | Программаны тормышка ашыру түбәндәге күрсәткечләрне саклап калырга мөмкинлек бирәчәк:<br><br>дәүләт һәм муниципаль идарә, мәгълүмат коммуникация һәм хезмәт күрсәтү өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт телләрендәге аудиовизуаль мәгълүматның нисбәте-50 процент / 50 процент;<br><br>квалификацияләрен күтәргән туган тел һәм дәүләт теле укытучыларының өлеше -100 процент;<br><br>республиканың яшь буынын милли мәдәниятләр кыйммәтләренә тарту максатларында үткәрелгән чараларда катнашкан балалар өлеше-елына 100 процент;<br><br>тел сәясәте өлкәсендә олимпиада хәрәкәтен һәм фәнни-тикшеренү эшчәнлеген колачлаган чараларда катнашучылар саны, үсә барган нәтиҗә белән, – елга 50 процент; |

| | |
|---|---|
| | хезмәт күрсәтү өлкәсендәге дәүләт предприятиеләрендә Татарстан Республикасының ике дәүләт телендә белешмә мәгълүматның булуы 100 процент тәшкил итәчәк. |

## I. Программаны гамәлгә ашыру өлкәсенә гомуми характеристика, аларны хәл итүгә Программа юнәлдерелгән проблемалар

Әлеге Программа Россия Федерациясе Конституциясе, «Россия Федерациясе халыклары телләре турында» 1991 елның 25 октябрендәге 1807-1 номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясе дәүләт теле турында» 2005 елның 1 июнендәге 53-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Президентының 2012 елның 19 декабрендәге 1666 номерлы Указы белән расланган 2025 елга кадәрге чорга Россия Федерациясе дәүләт милли сәясәте стратегиясе, Татарстан Республикасы Конституциясе, «Татарстан Республикасы дәүләт телләре һәм Татарстан Республикасында башка телләр турында» 1992 елның 8 июлендәге 1560-XII номерлы Татарстан Республикасы Законы һәм «Татарстан Республикасы дәүләт теле буларак татар телен куллану турында» 2013 елның 12 гыйнварындагы 1-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, шулай ук Татарстан Республикасы Президентының 2008 елның 3 июлендәге ПУ-312 номерлы Указы белән расланган Татарстан Республикасында дәүләт милли сәясәте концепциясе, Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасының башка законнары нигезендә эшләнгән һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 25 ноябрендәге 794 номерлы карары белән расланган 2014-2022 елларга Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү буенча Татарстан Республикасы дәүләт программасын гамәлгә ашыру кысаларында башкарылган эшне дәвам итәргә тиеш.

«Мәгарифне үстерү» Россия Федерациясе дәүләт программасы һәм 2016 - 2020 елларга «Татарстанда рус теле» ведомство максатчан программасы чаралары белән беррәттән, әлеге Программа Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү өчен оптималь шартлар тудыруга юнәлдерелгән.

Татарстанның үзенчәлеге булып, республика халкының күпмилләтле булуы һәм күпконфессиональлеге тора. Республикада 173 милләт вәкиле яши. Татарстанның иҗтимагый үсеше тыгыз этнокультур үзара тәэсир итешү һәм аның территориясендә яшәүче халыклар гореф-гадәтләренең бер-берсенә үтеп керүе белән характерлана.

Биектау муниципаль районында төрле милләт вәкилләре яши: татарлар - 64%, руслар - 34% һәм башкалар - 2%.

Программаны гамәлгә ашыру эше максатчан характерда. Эш кәгазьләре ике дәүләт телендә алып барыла. Гражданнарны шәхси мәсьәләләр буенча кабул итүләр, аларның гаризалары, шикаятьләре һәм үтенечләре белән эшләү ике дәүләт телендә алып барыла. Районда барлык киңәшмәләр, оештыру чаралары дәүләт телләрендә үткәрелә. Мәдәният, мәгариф, сәламәтлек саклау, социаль яклау учреждениеләренең, хезмәт күрсәтү объектларының эчке һәм тышкы бизәлеше Телләр турындагы закон таләпләренә туры китерелде.

Район республика башкаласы белән автобус элемтәсе белән тоташкан. Пассажирларга хезмәт күрсәтү рус һәм татар телләрендә алып барыла.

Районның сәүдә челтәрләрендә, халыкка хезмәт күрсәтү оешмаларында Татарстан Республикасының ике дәүләт телендә хезмәтләр күрсәтелә.

Районда «Высокогорские вести» / «Биектау хәбәрләре» газетасы басылып чыга. «Биектау ТВ» телевизион каналы эфирга 2013 елның мартыннан, атнага 2 сәгать (рус телендә 1 сәгать, татар телендә 1 сәгать) чыга башлады. «Биектау FM» радиоэфиры 100,2 ешлыгында татар телендә атнага 21 сәгать эшли.

Дәүләт телләрен өйрәнү мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләреннән башлана. Районның барлык мәктәпкәчә учреждениеләрендә балаларны Татарстан Республикасының ике дәүләт теленә өйрәтү буенча укыту-методик комплектлар кертелә. Районда 32 мәктәп эшли. Шуларның 15ендә белем бирү татар телендә. Мәктәп яшендәге балаларның милли составы мониторингы алып барыла. 2022/2023 уку елында районның гомуми белем бирү учреждениеләрендә 7391 укучы белем ала, шуларның 4331 е - татар, 1929 ы - рус, 958 е - катнаш гаилә вәкилләре, һәм башка милләтләр вәкилләре - 173 (үзбәкләр, таҗиклар, чувашлар, украиннар, әрмәннәр, марилар, азәрбайҗаннар, удмуртлар һ.б.).

Татар теле укытучылары саны - 60. Шулардан 14 кеше (23%) югары квалификация категориясенә, 43 кеше (71%) беренче категориягә ия.

Район мәктәпләрендә 62 рус теле һәм әдәбияты укытучысы эшли: аларның 20се югары категориягә ия, - 36 сы беренче категориягә ия.

Алдынгы педагогик тәҗрибәне тарату максатында, ай саен татар теле һәм әдәбияты, рус теле һәм әдәбияты укытучыларының семинарлары уздырыла. Татар теле һәм әдәбияты, рус теле һәм әдәбияты укытучыларының район методик берләшмәләре эше укытучыларның һөнәри, педагогик осталыгын арттыруга, укыту һәм тәрбияләү процессына яңа технологияләр кертүгә юнәлтелгән.

Сәләтле балалар белән актив эш алып барыла. Татар теле һәм әдәбияты буенча республика олимпиадасында район укучылары 9 призлы урын яуладылар. Татар теле һәм әдәбияты буенча Халыкара олимпиадасында – Гран-при, Минҗәләева Гөлинә (11 сыйныф, Мүлмә урта мәктәбе, Минһаҗетдинова Р.Ф.). Рус теленнән Халыкара олимпиада призеры - Хәйруллина Иркә (Мүлмә урта мәктәбе, укытучысы Шәрәфиева А.И.).

Ел саен язучылыр юбилейларына, туган тел айлыгына багышланган район чаралары уздырыла. Халыкара Туган тел көне (21 февраль) кысаларында район мәгариф учреждениеләрендә төрле чаралар уздырыла: «Милләтем – горурлыгым» туган телләр фестивале; танылган галим, теолог, философ, мәгърифәтче, җәмәгать эшлеклесе, педагог, журналист Галимҗан Барудиның 165 еллыгына (ТР Мәгариф һәм фән министрлыгы, ГАОУ ДПО ИРО РТ белән берлектә) багышланган төбәкара фәнни-тикшеренү конференциясе; «Туган телнең бәллүр чишмәсе» район фестивале һ.б. Сыйныфтан тыш һәм мәктәптән тыш эшне оештырганда, төрле милләт балалары мәнфәгатьләрен якынайтуга игътибар бирелә. Ел саен туган телләр айлыгы уздырыла. Укучыларның интеллектуаль һәм иҗади сәләтләрен ачыклау, татар һәм рус телләрен белү белән кызыксынучы мәктәп яшендәге балаларның санын арттыру максатында ел саен «Туган телем - Тукай теле», «Тере классика» конкурслары уздырыла. Бу

конкурсларда рус һәм татар телләрендә генә түгел, укучыларыбызның башка туган телләрендә дә шигырьләр яңгырый.

**Төбәкара хезмәттәшлек**

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының 2015 елның 22 октябрендәге 9475/15 номерлы боерыгы нигезендә Биектау муниципаль районы Башкортостан Республикасының Куюргазы районы, Тамбов өлкәсе, Марий Эл Республикасының Параньга районы белән хезмәттәшлек итә. Беркетелгән регионнар арасында милләтара мөнәсәбәтләрне ныгытуга багышланган чаралар ел саен планлаштырыла: уртак семинарлар үткәрү, укытучыларның педагогик тәҗрибәсен гомумиләштерү һәм тарату, дәреслекләр сатып алуда ярдәм итү һ.б. Алга таба да шулай ук безнең район укытучылары күрше төбәкләрдәге коллегаларына тиешле методик ярдәм күрсәтәчәкләр.

Хезмәттәшлек кысаларында түбәндәге чаралар уздырылды:

- Приморье краеның Надеждинский районы делегациясен кабул итү;
- Танылган галим, теолог, философ, мәгърифәтче, җәмәгать эшлеклесе, педагог, журналист Галимҗан Барудиның 165 еллыгына (ТР Мәгариф һәм фән министрлыгы, ГАОУ ДПО ИРО РТ, Бөтендөнья татар конгрессының Башкарма комитеты белән берлектә) багышланган төбәкара фәнни-тикшеренү конференциясе. Конференциянең читтән торып уздырылган турында 2022 елның 17 февралендә "Г.Баруди исемендәге 4 нче Биектау урта мәктәбе" МБОУ базасында Татарстан Республикасы һәм башка регионнар (Мордовия Республикасы, Башкортостан Республикасы, Чуваш Республикасы, Ульяновск, Төмән, Пермь, Самара, Новосибирск, Түбән Новгород өлкәләре) гомуми белем бирү оешмалары укучылары катнашты,;
- «Минем гаиләм алга, киләчәккә атлый» дигән туган телне саклап калу мәсьәләләре буенча әти-әниләр конференциясе (ГАОУ ДПО ИРО РТ һәм «Татар гаиләсе» иҗтимагый оешмасы белән берлектә) 2022 елның 27 апрелендә 1 нче Биектау урта мәктәбе базасында, Томск Мәгарифне үстерү институты ректоры Замятина Оксана Михайловна катнашында;
- Район делегациясенең Марий Эл Республикасы Параньга районы Куянка урта мәктәбе базасында, 2022 елның 15 декабрендә “Туган тел укытучысының яңартылган ФГОС ын гамәлгә ашыру шартларында эшчәнлеге” төбәкара семинар-киңәшмәсендә катнашуы;

2025 елга кадәр чорга Россия Федерациясе дәүләт милли сәясәте стратегиясе нигезендә төп максатчан юнәлешләр булып гомумроссия гражданлык үзаңын ныгыту, этномәдәни күптөрлелекне саклап калу һәм үстерү, милли һәм милләтара мөнәсәбәтләрне гармонияләштерү тора. Татарстан Республикасында традицион рәвештә гомумроссия гражданлык һәм Татарстан тәңгәллеген ныгытуга, мәдәни һәм тел традицияләрен трансляцияләүгә, яшь буында туган телгә һәм рухи мираска мәхәббәт тәрбияләүгә һәм этник тәңгәллеген формалаштыруга аерым игътибар бирелә. Туган телләрдә сөйләм юнәлешендәге лагерьларга, профиль сменаларына, конференцияләргә һәм олимпиадаларга карата даими кызыксыну эштә әлеге юнәлешнең кирәкле булуын һәм дәвам итүне таләп итүен күрсәтә. Шулай ук иҗтимагый оешмалар инициативаларын хуплау, яңа заманча яшьләр һәм балалар проектларын булдыру да мөһим.

Татарстаннан читтә татар телен, мәдәниятен, татарларның үзенчәлекләрен

саклауга һәм үстерүгә ярдәм итү буенча республиканың конституциячел бурычларын үтәү мөһим юнәлеш булып тора. Татар халкының үсеш тарихы аның территориаль дисперслыгын тәэмин итә. Глобальләшү шартларында Россиядә дә, бөтен дөньяда да татарларның мәдәни ассимиляциясе процесслары көчәя, бу татар теле аларның берсүзсез трансляторы булып торган милли үзенчәлекләрне һәм милли традицияләрне югалтуда тискәре чагылыш таба. Туган телен белгән татарлар саны кимү тенденциясе саклана. Татар телен белү дәрәҗәсенең кимүе белән беррәттән, татар телен куллану даирәсенең кимүе күзәтелә, шул исәптән эштә һәм көнкүрештә дә. Бу процесслар татар телендә белем бирүче мәктәпләр саны кимү, югары белем бирүче мәгариф оешмалары каршындагы татар бүлекчәләре челтәре кыскару, туган татар телендә белем бирү системасы эшчәнлеге өчен хокукый һәм институциональ мөмкинлекләрне югалту белән озатыла. Бу шартларда татар иҗтимагый оешмаларына һәм мәгариф оешмаларына Татарстаннан читтә татар телен өйрәнүдә һәрьяклап ярдәм итү аеруча кирәк.

Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасы халыкларының башка телләрен саклау, өйрәнү һәм үстерү мәсьәләләре Татарстан Республикасында дәүләт милли сәясәтен гамәлгә ашыруның өстенлекле юнәлешләре рәтендә тора.

## II. Төп максат, максатка ирешү һәм бурычларны хәл итү күрсәткечләре (индикаторлары), программаның төп көтелгән ахыргы нәтиҗәләрен, аны гамәлгә ашыру срокларын һәм этапларын тасвирлау

Программа Татарстан Республикасы дәүләт телләре һәм Татарстан Республикасында башка телләр өлкәсендә дәүләт сәясәтенең төп принциплары нигезендә эшләнде, алар телләрнең үсешен һәм гармонияле хезмәттәшлеген, республикада яшәүче халыклар вәкилләренең милли-тел мәнфәгатьләренең тотрыклы балансын саклауны күздә тота.

Программаның максаты – Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районында татар, рус һәм башка телләрне, шулай ук Татарстан Республикасыннан читтә (беркетелгән төбәкләрдә) татар телен саклау, өйрәнү һәм үстерү өчен шартлар тудыру.

Программа чаралары Татарстан Республикасында телләрне саклау һәм үстерүнең Программа бурычлары нигезендә барлык төп аспектларын колачлый:

- Татарстан Республикасы дәүләт телләре һәм Татарстан Республикасында яшәүче башка халыкларның телләре эшчәнлеген һәм өйрәнүне оештыру-хокукый һәм аналитик тәэмин итү;
- Татарстан Республикасы дәүләт телләре буларак татар һәм рус телләренең паритетлы кулланылуына ярдәм итү;
- Татар һәм рус телләрен, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районында яшәүче халыкларның башка телләрен өйрәнүнең тулы системасын үстерү; би-һәм полилингваль белем бирү системаларын оештыру һәм укыту-методик озата бару;
- Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне популярлаштыруга һәм Татарстан Республикасыннан читтә

(беркетелгән регионнарда) зур социаль әһәмиятле чаралар үткәрү;

- Интернет-киңлектә уңайлы тел мохите булдыру һәм массакүләм мәгълүмат чараларында туган телләрне популярлаштыру.

Программаны га мәлгә ашыруның гомуми срогы: 2023 – 2030 еллар.

Программа индикаторлары

Программаның индикаторлары булып тора:

| Ахыргы нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары, үлчәү берәмлекләре | 2023 ел | 2024 ел | 2025 ел | 2026 ел | 2027 ел | 2028 ел | 2029 ел | 2030 ел |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 |
| Дәүләт һәм муниципаль идарә, мәгълүмат коммуникация һәм Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы хезмәт күрсәтү өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт телләрендәге аудиовизуаль мәгълүматның нисбәте, процент | 50/50 | 50/50 | 50/50 | 50/50 | 50/50 | 50/50 | 50/50 | 50/50 |
| Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районында дәүләт һәм муниципаль идарә өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә эш кәгазьләрен алып бару өлеше, процент | 100/100 | 100/100 | 100/100 | 100/100 | 100/100 | 100/100 | 100/100 | 100/100 |
| Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районында республика яшь буынын милли мәдәниятләр кыйммәтләренә тарту максатларында үткәрелгән чараларда катнашкан балалар өлеше, процент | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 |
| Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районында тел сәясәте өлкәсендә олимпиада хәрәкәтен һәм фәнни-тикшеренү эшчәнлеген | 50 | 50 | 50 | 50 | 50 | 50 | 50 | 50 |

| Ахыргы нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары, үлчәү берәмлекләре | 2023 ел | 2024 ел | 2025 ел | 2026 ел | 2027 ел | 2028 ел | 2029 ел | 2030 ел |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 |
| колачлаган чараларда катнашучылар саны, процентов | | | | | | | | |
| Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районында тел вәзгыяте һәм Программаны тормышка ашыру барышы турында массакүләм мәгълүмат чараларында басмалар саны, берәмлек | 150 | 150 | 150 | 150 | 150 | 150 | 150 | 150 |
| Биектау муниципаль районында этно-тел вәзгыяте буенча һәм Программаны үтәүнең нәтиҗәлелеген анализлау буенча үткәрелгән мониторинглар саны, берәмлек | 2 | 2 | 3 | 2 | 2 | 2 | 3 | 2 |

## III. Программаны ресурслар белән тәэмин итү

Программаны финанслауның гомуми күләме Биектау муниципаль районы бюджеты акчалары исәбеннән, өстәмә керемнәр булганда, 4 000 000 сум тәшкил итә, шул исәптән:

2023 елда – 500 000,
2024 елда - 500 000,
2025 елда - 500 000,
2026 елда - 500 000,
2027 елда – 500 000,
2028 елда - 500 000,
2029 елда – 500 000,
2030 елда – 500 000.

Искәрмә: финанслау күләмнәре фараз характерында һәм Татарстан Республикасы бюджеты мөмкинлекләрен исәпкә алып, ел саен төзәтмәләр кертелергә тиеш.

Программа чараларын гамәлгә ашыруга чараларны башкаручыларның төп эшчәнлеген финанслауга бүлеп бирелә торган акчаларны, бюджеттан тыш акчаларны (эшкуарлар, иганәчеләр акчалары) һәм муниципаль берәмлек бюджеты акчаларын файдалану күздә тотыла.

## IV. Программаны гамәлгә ашыру механизмы

Программаны гамәлгә ашыру барышында аны эшләүче - координатор (Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы башкарма комитеты) төп башкаручыларның үзара хезмәттәшлеген тәэмин итә.

Программаны гамәлгә ашыруда катнашучы бүлекләр ел саен Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы башкарма комитетына аның үтәлеше турында мәгълүмат тапшыра.

## V. Программаның социаль-икътисади нәтиҗәлелеге тасвирламасы

Программаның нәтиҗәлелеге билгеләнгән срокларда чараларны үтәү дәрәҗәсе буенча бәяләнә. Программаның нәтиҗәлелеген бәяләү өчен, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты бүлекләренең агымдагы хисаплылык материаллары кулланыла.

Программада каралган чараларны гамәлгә ашыру рухи байлыкны арттыруга; Биектау муниципаль районында яшәүче халыкларның телен, әдәбиятын һәм мәдәниятен популярлаштыручы агарту чараларының халык өчен үтемлелеген арттыруга, Татарстан Республикасы дәүләт телләренең функциональлеген күтәрүгә ярдәм итәчәк.

Дини һәм интеллектуаль өлкәне үстерүгә бәйле Программаның үзенчәлеген исәпкә алып, икътисадый нәтиҗәлелекне билгеләү күздә тотылмый.

Программа чараларын гамәлгә ашыру мәгариф оешмаларының белем бирү һәм тәрбия эшчәнлегенә булышырга һәм аны үстерергә, педагогның социаль статусын күтәрергә мөмкинлек бирәчәк, халыкның туган телләрне өйрәнүдә һәм үстерүдә конституциячел хокукларын яклауга ярдәм итәчәк, Татарстан Республикасының тел законнарын гамәлгә ашыру буенча чараларны координацияләргә һәм аларны оптимальләштерергә ярдәм итәчәк.

«2023 - 2030 елларга Татарстан Республикасының Биектау муниципаль районында Татарстан Республикасының дәүләт телләрен һәм башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» муниципаль программасына 1 нче кушымта

**«2023 - 2030 елларга Татарстан Республикасының Биектау муниципаль районында Татарстан Республикасының дәүләт телләрен һәм башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» муниципаль программасын гамәлгә ашыруны ресурслар белән тәэмин итү**

| Бурыч исеме | Финанслау чыганагы | 2023 ел | 2024 ел | 2025 ел | 2026 ел | 2027 ел | 2028 ел | 2029 ел | 2030 ел | Барлык чаралар |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 |
| 1 бурыч. Татарстан Республикасы дәүләт телләре һәм Татарстан Республикасында яшәүче башка халыкларның телләре куллануны һәм өйрәнүне оештыру-хокукый һәм аналитик тәэмин итү | Өстәмә керемнәр булганда муниципаль бюджет | 0 | 0 | 0 | 0 | 0 | 0 | 0 | 0 | 0 |
| 2 бурыч. Татарстан Республикасы дәүләт телләре буларак татар һәм рус телләренең паритет кулланылышына ярдәм итү | Өстәмә керемнәр булганда муниципаль бюджет | 0 | 0 | 0 | 0 | 0 | 0 | 0 | 0 | 0 |

| Бурыч исеме | Финанслау чыганагы | 2023 ел | 2024 ел | 2025 ел | 2026 ел | 2027 ел | 2028 ел | 2029 ел | 2030 ел | Барлык чаралар |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 |
| 3 бурыч. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районында яшәүче халыкларның татар һәм рус телләрен, башка телләрен өйрәнүнең тулы системасын үстерү; би- һәм полилингваль белем бирү системаларын оештыру һәм укыту-методик озату | Өстәмә керемнәр булганда муниципаль бюджет | 0 | 0 | 0 | 0 | 0 | 0 | 0 | 0 | 0 |
| 4 бурыч. Татарстан республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан республикасында башка телләрне популярлаштыруга юнәлдерелгән иҗтимагый әһәмиятле эре чаралар (беркетелгән регионнарда) үткәрү | Өстәмә керемнәр булганда муниципаль бюджет | 500,000 | 500,000 | 500,000 | 500,000 | 500,000 | 500,000 | 500,000 | 500,000 | 500,000 |
| 5 бурыч. Интернет-киңлектә уңайлы тел мохите булдыру һәм массакүләм мәгълүмат чараларында туган телләрне популярлаштыру | Өстәмә керемнәр булганда муниципаль бюджет | 0 | 0 | 0 | 0 | 0 | 0 | 0 | 0 | 0 |

| Бурыч исеме | Финанслау чыганагы | 2023 ел | 2024 ел | 2025 ел | 2026 ел | 2027 ел | 2028 ел | 2029 ел | 2030 ел | Барлык чаралар |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 |
| **Программа буенча барлыгы** | **Өстәмә керемнәр булганда муниципаль бюджет** | **500,000** | **500,000** | **500,000** | **500,000** | **500,000** | **500,000** | **500,000** | **500,000** | **500,000** |

«2023 - 2030 елларга Татарстан Республикасының Биектау муниципаль районында Татарстан Республикасының дәүләт телләрен һәм башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» муниципаль программасына 2 нче кушымта

**«2023 - 2030 елларга Татарстан Республикасының Биектау муниципаль районында Татарстан Республикасының дәүләт телләрен һәм башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» муниципаль программасының максаты, бурычлары, нәтиҗәләрен бәяләү индикаторлары һәм аның чараларын финанслау**

| Төп чараларның атамалары | Башкаручылар | Төп чараларны үтәү срогы | Ахыргы нәтиҗәләрне бәяләү күрсәткечләре, үлчәү берәмлеге | Индикатор күрсәткечләре | | | | | | | | | Өстәмә керемнәр булганда, бюджет чаралары исәбеннән финанслау, мең сум | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 2022 ел (база) | 2023 ел | 2024 ел | 2025 ел | 2026 ел | 2027 ел | 2028 ел | 2029 ел | 2030 ел | 2023 ел | 2024 ел | 2025 ел | 2026 ел | 2027 ел | 2028 ел | 2029 ел | 2030 ел |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 | 15 | 16 | 17 | 18 | 19 | 20 | 21 |
| **Татарстан Республикасы дәүләт телләре һәм Татарстан Республикасында яшәүче башка халыкларның телләре эшчәнлеген һәм өйрәнүне оештыру-хокукый һәм аналитик тәэмин итү** | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| Татарстан Республикасы телләре турындагы законнарны гамәлгә ашыру буенча муниципаль комиссия эшчәнлеген оештыру | Башкарма комитет | 2023 – 2030 еллар | комиссияләр саны, берәмлек | 1 | 1 | 1 | 1 | 1 | 1 | 1 | 1 | 1 | Төп эшчәнлек | | | | | | | |
| 2023 - 2030 елларга муниципаль программаны эшләү, раслау һәм гамәлгә ашыру | Башкарма комитет | 2023 –2030 еллар | кабул ителгән программалар саны, берәмлек | 1 | 1 | 1 | 1 | 1 | 1 | 1 | 1 | 1 | Төп эшчәнлек | | | | | | | |
| Татар һәм рус телләрендә рәсми сайтка ярдәм | Башкарма комитет | 2023 – 2030 еллар | рус һәм татар телләрендәге язмалар саны, процент | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | Төп эшчәнлек | | | | | | | |
| Татарстан | Башкарма | 2023 | рус һәм | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | Төп эшчәнлек | | | | | | | |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 | 15 | 16 | 17 | 18 | 19 | 20 | 21 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары һәм аның карамагындагы учреждениеләр исемнәре белән элмә такталарның орфография һәм пунктуация кагыйдәләренә, татар һәм рус телләрендәге текстларының тәңгәллеген тәэмин итү | комитет | –2030 еллар | татар телләренд әге элмә саны, процент | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| Норматив хокукый актларны, җирле үзидарә органнарының башка документларын Татарстан Республикасы дәүләт телләренә күчерүне гамәлгә ашыру | Башкарма комитет | 2023 –2030 еллар | рус һәм татар телләренд ә норматив хокукый актлар, башка документ лар күләме, процент | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | Төп эшчәнлек | | | | | | | |
| Барысы | | | | | | | | | | | | | 0 | 0 | 0 | 0 | 0 | 0 | 0 | 0 |
| Нәтиҗәдә | | | | | | | | | | | | | 0 | | | | | | | |
| **Татарстан Республикасы дәүләт телләре буларак татар һәм рус телләренең паритет кулланылышына ярдәм итү** | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районында теле- һәм радиотапшыруларны Татарстан Республикасының ике дәүләт телендә гамәлгә ашыру | «Татмедиа» ААҖ Биектау филиалы | 2023 –2030 еллар | ТР тапшыруларның гомуми күләменд ә рус һәм татар тел ләрендә тапшыру лар өлеше, проц ент | 50/50 | 50/50 | 50/50 | 50/50 | 50/50 | 50/50 | 50/50 | 50/50 | 50/50 | Төп эшчәнлек | | | | | | | |
| Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә эш кәгазьләрен алып бару | Башкарма комитет | 2023 –2030 еллар | ТР дәүләт телләренд ә билгеләнгән тәртиптә | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | Төп эшчәнлек | | | | | | | |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 | 15 | 16 | 17 | 18 | 19 | 20 | 21 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | бастырылган норматив хокукый актлар өлеше, процент | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| | | | татар телендә кергән органнар (оешмалар) мөрәҗәгатьләренә эш кәгаьләрендә татар телендә башкарылган документлар өлеше, процент | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | Төп эшчәнлек | | | | | | | |
| Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә тышкы һәм эчке визуаль мәгълүмат чараларын рәсмиләштерү | Башкарма комитет | 2023–2030 еллар | гомуми мәгълүмат күләмендә ике дәүләт телендә рәсмиләштерелгән тышкы һәм эчке визуаль мәгълүмат чаралары өлеше, процент | 60 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | Төп эшчәнлек | | | | | | | |
| Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә юл күрсәткечләрен рәсмиләштерү | Башкарма комитет | 2023–2030 еллар | Татарстан Республикасының ике дәүләт | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | Төп эшчәнлек | | | | | | | |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 | 15 | 16 | 17 | 18 | 19 | 20 | 21 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | телендә куелган юл күрсәткечләре саны, процент | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә урам күрсәткечләрен рәсмиләштерү | Башкарма комитет | 2023–2030 еллар | урам күрсәткечләренең гомуми санында ике дәүләт телендә рәсмиләштерелгән урам күрсәткечләренең өлеше, процент | 75 | 80 | 82 | 84 | 86 | 88 | 90 | 92 | 94 | Төп эшчәнлек | | | | | | | |
| Чыгарыла торган продукцияне Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә этикеткалар, ярлыклар, инструкцияләр белән тәэмин итүдә ярдәм | Башкарма комитет | 2023–2030 еллар | Татарстан Республикасында чыгарыла торган продукциянең гомуми күләмендә Татарстан Республикасы ике дәүләт телендә этикеткасы, ярлыклары, инструкцияләре булган продукция өлеше, процент | 72 | 73 | 74 | 75 | 76 | 77 | 78 | 79 | 80 | Төп эшчәнлек | | | | | | | |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 | 15 | 16 | 17 | 18 | 19 | 20 | 21 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Халыкка Татарстан Республикасының ике дәүләт телендә сәүдә хезмәткәрләре тарафыннан хезмәт күрсәтү | Башкарма комитет | 2023 –2030 еллар | Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә халыкка хезмәт күрсәтү өлеше, процент | 98 | 98 | 98 | 98 | 98 | 98 | 98 | 98 | 98 | Төп эшчәнлек | | | | | | | |
| Хезмәт күрсәтү өлкәсе предприятиеләрендә Татарстан Республикасының ике дәүләт телендә белешмә мәгълүмат булуны тәэмин итү | Башкарма комитет | 2023 –2030 еллар | Татарстан Республикасының ике дәүләт телендә белешмә мәгълүмат өлеше, процент | 95 | 97 | 98 | 98 | 98 | 98 | 98 | 98 | 98 | Төп эшчәнлек | | | | | | | |
| Татар телендә түләүсез юридик ярдәм алуга гражданнарның хокукларын гамәлгә ашыру өчен шартлар тудыру | Башкарма комитет | 2023 –2030 еллар | татар телендә мөрәҗәгать иткән гражданнар мөрәҗәгатьләренә татар телендә күрсәтелгән хезмәтләр өлеше, процент | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | Төп эшчәнлек | | | | | | | |
| «Вконтакте» социаль челтәрендә рус һәм татар телләрендә рәсми битне озатып бару | «Татмедиа» ААҖ Биектау филиалы | 2023 –2030 еллар | Рус һәм татар телләрендә басмалар, процент | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | Төп эшчәнлек | | | | | | | |
| Барысы | | | | | | | | | | | | | 0 | 0 | 0 | 0 | 0 | 0 | 0 | 0 |
| Нәтиҗәдә | | | | | | | | | | | | | 0 | | | | | | | |
| **Татар һәм рус телләрен, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районында яшәүче башка халыклар телләрен өйрәнүнең бербөтен системасын үстерү; би- һәм полилингваль белем бирү системаларын оештыру һәм укыту-методик озата бару** | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| Гомуми белем бирү | «ТР | 2023 | оештыры | 2 | 2 | 2 | 2 | 2 | 2 | 2 | 2 | 2 | Төп эшчәнлек | | | | | | | |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 | 15 | 16 | 17 | 18 | 19 | 20 | 21 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| оешмаларының туган (татар) теле һәм әдәбияты укытучылары өчен семинарлар оештыру һәм алып бару | Биектау муниципаль районы башкарма комитетының мәгариф бүлеге» МКУ | –2030 | лган семинарлар саны | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| Гомуми белем бирү оешмаларының рус теле һәм әдәбияты укытучылары өчен семинарлар оештыру һәм үткәрү | «ТР Биектау муниципаль районы башкарма комитетының мәгариф бүлеге» МКУ | 2023–2030 еллар | оештырылган семинарлар саны | 2 | 2 | 2 | 2 | 2 | 2 | 2 | 2 | 2 | Төп эшчәнлек | | | | | | | |
| Рус һәм татар телләре укытучыларының квалификациясен күтәрү | «ТР Биектау муниципаль районы башкарма комитетының мәгариф бүлеге» МКУ | 2023–2030 годы | квалификация күтәрү курсларын ел саен уза торган педагогик кадрлар саны, процент | 35 | 35 | 35 | 35 | 35 | 35 | 35 | 35 | 35 | Төп эшчәнлек | | | | | | | |
| Башлангыч, төп һәм урта белем бирү оешмаларында телләр турындагы законнарны гамәлгә ашыруга ярдәм | «ТР Биектау муниципаль районы башкарма комитетының мәгариф бүлеге» МКУ | 2023–2030 еллар | уздырылган чаралар саны, берәмлек | 5 | 5 | 5 | 5 | 5 | 5 | 5 | 5 | 5 | Төп эшчәнлек | | | | | | | |
| Россия Федерациясенең | «ТР Биектау | 2023–2030 | Россия Федераци | 1 | 1 | 1 | 1 | 1 | 1 | 1 | 1 | 1 | Төп эшчәнлек | | | | | | | |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 | 15 | 16 | 17 | 18 | 19 | 20 | 21 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| беркетелгән төбәкләрендә татар мәгърифәте көннәрен үткәрүдә катнашу | муниципаль районы башкарма комитетының мәгариф бүлеге» МКУ | еллар | ясе төбәкләрендә уздырылган чаралар саны, берәмлек | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| Татарстан Республикасы мәгариф оешмаларын Россия Федерациясе халыклары телләрендә мәгълүмати ресурслар һәм сәнгать әдәбияты белән тәэмин итү | «ТР Биектау муниципаль районы башкарма комитетының мәгариф бүлеге» МКУ | 2023 –2030 еллар | сатып алынган әдәбият саны, берәмлек | 200 | 200 | 200 | 200 | 200 | 200 | 200 | 200 | 200 | Төп эшчәнлек | | | | | | | |
| Укучылар өчен татар теле буенча сөйләм практикасы белән регионара сменаларны оештыруга һәм үткәрүгә ярдәм итү | «ТР Биектау муниципаль районы башкарма комитетының мәгариф бүлеге» МКУ | 2023 –2030 еллар | татар телендә сөйләм практикасы белән сменада катнашучылар саны, кеше/ сменалар саны, берәмлек | 10/3 | 10/3 | 10/3 | 10/3 | 10/3 | 10/3 | 10/3 | 10/3 | 10/3 | Төп эшчәнлек | | | | | | | |
| Татар теле буенча Халыкара олимпиадада катнашу | «ТР Биектау муниципаль районы башкарма комитетының мәгариф бүлеге» МКУ | 2023 –2030 еллар | катнашучылар саны, кеше | 5 | 5 | 5 | 5 | 5 | 5 | 5 | 5 | 5 | Төп эшчәнлек | | | | | | | |
| Г.Тукайга | «ТР | 2023 | катнашуч | 5 | 5 | 5 | 5 | 5 | 5 | 5 | 5 | 5 | Төп эшчәнлек | | | | | | | |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 | 15 | 16 | 17 | 18 | 19 | 20 | 21 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| багышланган Бөтенроссия туган тел форумында катнашу | Биектау муниципаль районы башкарма комитетының мәгариф бүлеге» МКУ | –2030 еллар | ылар саны, кеше | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| Рус теле буенча халыкара олимпиадада туган (рус булмаган) телле мәктәпләр укучылары өчен катнашу | «ТР Биектау муниципаль районы башкарма комитетының мәгариф бүлеге» МКУ | 2023 –2030 еллар | катнашучылар саны, кеше | 3 | 3 | 3 | 3 | 3 | 3 | 3 | 3 | 3 | Төп эшчәнлек | | | | | | | |
| Барлыгы | | | | | | | | | | | | | 0 | 0 | 0 | 0 | 0 | 0 | 0 | 0 |
| Нәтиҗәдә | | | | | | | | | | | | | 0 | | | | | | | |
| **Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне популярлаштыруга һәм Татарстан Республикасыннан читтә (беркетелгән регионнарда) социаль әһәмиятле зур чаралар үткәрү** | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| “Мин татарча сөйләшәм” («Я говорю по-татарски») республика бәйге-акциясендә катнашу | «ТР Биектау муниципаль районы башкарма комитетының мәгариф бүлеге» МКУ | 2023 –2030 еллар | катнашучылар саны, кеше | | | | | | | | | | Төп эшчәнлек | | | | | | | |
| Балалар яшүсмерләр театрларының республика фестивален оештыру һәм уздыру | «ТР Биектау муниципаль районы башкарма комитетының мәгариф | 2023 –2030 еллар | катнашучылар саны, кеше | 500 | 500 | 500 | 500 | 500 | 500 | 500 | 500 | 500 | Төп эшчәнлек | | | | | | | |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 | 15 | 16 | 17 | 18 | 19 | 20 | 21 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | бүлеге» МКУ | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| Яшь шагыйрьләр һәм язучыларның «Илһам» («Вдохновение») бөтенроссия конкурсын оештыру һәм уздыру | «ТР Биектау муниципаль районы башкарма комитетының мәгариф бүлеге» МКУ | 2023–2030 еллар | катнашучылар саны, кеше | 600 | 600 | 600 | 600 | 600 | 600 | 600 | 600 | 600 | Төп эшчәнлек | | | | | | | |
| Бөтенроссия, төбәкара, республика конференцияләрендә, конкурсларда, фестивальләрдә катнашу һ.б. | «ТР Биектау муниципаль районы башкарма комитетының мәгариф бүлеге» МКУ | | катнашучылар саны, кеше | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | Төп эшчәнлек | | | | | | | |
| "Тере классика" Бөтенроссия мәктәп укучылары конкурсында катнашу | «ТР Биектау муниципаль районы башкарма комитетының мәгариф бүлеге» МКУ | 2023–2030 еллар | катнашучылар саны, кеше | 20 | 20 | 20 | 20 | 20 | 20 | 20 | 20 | 20 | Төп эшчәнлек | | | | | | | |
| А.С.Пушкинның туган көненә карата ел саен уздырыла торган чаралар үткәрү | «ТР Биектау муниципаль районы башкарма комитетының мәгариф бүлеге» | 2023–2030 еллар | катнашучылар саны, кеше | 150 | 150 | 150 | 150 | 150 | 150 | 150 | 150 | 150 | Төп эшчәнлек | | | | | | | |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 | 15 | 16 | 17 | 18 | 19 | 20 | 21 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | МКУ | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| Татар теле буенча тоталь диктант оештыру һәм үткәрү | «ТР Биектау муниципаль районы башкарма комитетының мәгариф бүлеге» МКУ «ТР Биектау муниципаль районы башкарма комитетының мәдәният бүлеге» МКУ | 2023 –2030 еллар | катнашучылар саны, кеше | 2000 | 2000 | 2000 | 2000 | 2000 | 2000 | 2000 | 2000 | 2000 | Төп эшчәнлек | | | | | | | |
| Рус теле буенча «Тоталь диктант» халыкара белем бирү акциясе | «ТР Биектау муниципаль районы башкарма комитетының мәгариф бүлеге» МКУ | 2023 –2030 еллар | катнашучылар саны, кеше | 250 | 250 | 250 | 250 | 250 | 250 | 250 | 250 | 250 | Төп эшчәнлек | | | | | | | |
| Туган телләр укытучыларының Бөтенроссия конкурсын оештыру һәм үткәрү | «ТР Биектау муниципаль районы башкарма комитетының мәгариф бүлеге» МКУ | 2023 –2030 еллар | катнашучылар саны, кеше | 1 | 1 | 1 | 1 | 1 | 1 | 1 | 1 | 1 | Төп эшчәнлек | | | | | | | |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 | 15 | 16 | 17 | 18 | 19 | 20 | 21 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Рус һәм татар телләрен популярлаштыру максатларында шигырь уку муниципаль конкурсларын, конференцияләр, фестивальләр үткәрү | «ТР Биектау муниципаль районы башкарма комитетының мәгариф бүлеге» МКУ «ТР Биектау муниципаль районы башкарма комитетының мәдәният бүлеге» МКУ | 2023 –2030 еллар | катнашучылар саны, кеше | 4 | 4 | 4 | 4 | 4 | 4 | 4 | 4 | 4 | 450 | 450 | 450 | 450 | 450 | 450 | 450 | 450 |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 | 15 | 16 | 17 | 18 | 19 | 20 | 21 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Халыкара туган тел көнен оештыру һәм үткәрү | «ТР Биектау муниципаль районы башкарма комитетының мәгариф бүлеге» МКУ «ТР Биектау муниципаль районы башкарма комитетының мәдәният бүлеге» МКУ | 2023 –2030 еллар | уздырылган чаралар саны | 50 | 50 | 50 | 50 | 50 | 50 | 50 | 50 | 50 | 50 | 50 | 50 | 50 | 50 | 50 | 50 | 50 |
| Барысы | | | | | | | | | | | | | 500 | 500 | 500 | 500 | 500 | 500 | 500 | 500 |
| Нәтиҗәдә | | | | | | | | | | | | | 500,000 | | | | | | | |
| **Интернет-киңлектә уңайлы тел мохите булдыру һәм массакүләм мәгълүмат чараларында туган телләрне популярлаштыру** | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| Массакүләм мәгълүмат чаралары аша программа чараларын үтәүнең барышы турында халыкка даими мәгълүмат бирү | Татмедиа | 2023 –2030 еллар | СМИда программаларны гамәлгә ашыру һәм үтәү барышы турында язмалар саны, берәмлек | 500 | 500 | 500 | 500 | 500 | 500 | 500 | 500 | 500 | Төп эшчәнлек | | | | | | | |
| Татарстан Республикасы халыклары телләрен саклау турында | Татмедиа | 2023 –2030 еллар | СМИда язмалар саны, берәмлек | 500 | 500 | 500 | 500 | 500 | 500 | 500 | 500 | 500 | Төп эшчәнлек | | | | | | | |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 | 15 | 16 | 17 | 18 | 19 | 20 | 21 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| материаллар әзерләү һәм аларны СМИда бастырып чыгару | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| Барысы | | | | | | | | | | | | | 0 | 0 | 0 | 0 | 0 | 0 | 0 | 0 |
| Нәтиҗәдә | | | | | | | | | | | | | 0 | | | | | | | |
| **Программа буенча барысы** | | | | | | | | | | | | | **500,000** | **500,000** | **500,000** | **500,000** | **500,000** | **500,000** | **500,000** | **500,000** |
| **Программа буенча барлыгы** | | | | | | | | | | | | | **500,000** | | | | | | | |

**Файдаланылган кыскартылмалар исемлеге:**

Башкарма комитет – Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы башкарма комитеты;

«ТР Биектау муниципаль районы башкарма комитетының мәгариф бүлеге» МКУ – «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы башкарма комитетының мәгариф бүлеге» муниципаль казна учреждениесе;

«ТР Биектау муниципаль районы башкарма комитетының мәдәният бүлеге» МКУ – «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы башкарма комитетының мәдәният бүлеге» муниципаль казна учреждениесе;

СМИ –массакүләм мәгълүмат чаралары;

Татмедиа – «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр буенча республика агентлыгы.

_________________________________